КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 март г.Казань № 206

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс үткәрү турында» 2018 ел, 28 март, 181 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс үткәрү турында» 2018 ел, 28 март, 181 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Педагог эшчәнлегендә ирешкән казанышлары өчен Татарстан Республикасы иң яхшы укытучыларына премияләр бирүгә конкурс үткәрү турында»;

1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Педагогик эшчәнлегендә ирешкән казанышлары өчен иң яхшы укытучыларга премияләр турында» 2018 ел, 28 ноябрь, 679 нчы Указы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Педагогик эшчәнлегендә ирешкән казанышлары өчен иң яхшы укытучыларга премияләр турында» 2018 ел, 28 ноябрь, 679 нчы Указын тормышка ашыру чаралары һәм Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 2017 ел, 20 май, 606 нчы карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2018 ел, 29 декабрь, 1739 нчы карары нигезендә педагог эшчәнлегендә ирешкән казанышлары өчен Татарстан Республикасы иң яхшы укытучыларына премияләр бирүгә конкурс үткәрүне;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурс йомгаклары буенча җиңүчеләр исемлеген раслый һәм аны педагог эшчәнлегендә ирешкән казанышлары өчен иң яхшы укытучыларга премияләр түләү өчен, агымдагы елның 15 июленнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына кертә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин